**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ КАМСКО-УСТЬИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАМА ТАМАГЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

ул. Калинина, д.31,
пгт. Камское Устье, 422820

Калинин урамы, 31 йорт,
штп. Кама Тамагы, 422820

тел.: (884377) 2-18-85, факс: 2-20-70, e-mail: Kamuste.Ispolkom@tatar.ru, http://kamskoye-ustye.tatarstan.ru.

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 елның 14 ноябре № 1177

«Ваклап сату базарын оештыру хокукына рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 29 декабрендәге 1156 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 15 августындагы 1415 номерлы карары нигезендә Кама Тамагы муниципаль районының Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. «Ваклап сату базарын оештыру хокукына рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 29 декабрендәге 1156 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешне кертергә:

1.1. 3.3.2.1 пунктындагы 11 абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«11. Гариза бирүченең формалаштырылган электрон формадагы запросының һәр юлын тутыру барышында, формат - логик тикшерү, органнар (оешма) билгеләгән таләпләр нигезендә, автомат рәвештә бердәм портал тарафыннан башкарыла. Бердәм портал тарафыннан, тутырылган электрон формадагы запросның хаталы юллары ачыкланганда, ачыкланган хатаның характеры һәм аны бетерү тәртибе, гариза бирүчегә мәгълүмати хәбәр итү юлы белән җиткерелә».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Кама Тамагы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары вазифаларын башкаручы (инфраструктура үсеше, төзекләндерү һәм ТКХ буенча) Ф.М. Мөхәммәдуллинага йөкләргә.

Җитәкче вазыйфасын башкаручы М.Х. Хәбибуллова